ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 декабрь, 2025 ел № 3/7

Шәһәр Советының җирле салымнар турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Салым кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турында Нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 9 ноябрендәге 11/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2016 елның 15 декабрендәге 13/7, 2017 елның 15 декабрендәге 21/7, 2018 елның 21 февралендәге 23/9, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/6, 2019 елның 7 октябрендәге 33/6, 2020 елның 21 февралендәге 37/6, 2022 елның 22 августындагы 16/8, 2022 елның 2 ноябрендәге 17/7, 2023 елның 25 октябрендәге 27/7, 2023 елның 28 декабрендәге 29/5, 2025 елның 23 июлендәге 44/6 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 4 пунктның 15 пунктчасындагы дүртенче, бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге 4.1. пункт өстәргә:

«4.1. Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә, салым ташламасы салым түләүче сайлаган бер салым салу объектына бирелә.

Салым ташламасына хокуклы салым түләүче сайланган салым салу объекты турында язмача хәбәр тапшырмаса, салым ташламасы салым салуның максималь суммадагы бер объектына карата бирелә.».

2. Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024 елның 30 октябрендәге 37/6 номерлы Карарының 4 пунктын көчен югалткан дип танып, үзгәреш кертергә

3. Әлеге Карар 2026 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев